**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«29» декабрь 2025 ел　　　Күзкәй авылы　　　№ 13

2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　Э.Р. Гәрәев

Исполнительный комитет Кузкеевского сельского поселения
ИНН 1639032350
ОГРН 1061662004911

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның «29» декабрь 13 номерлы карары белән расланган

2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасы

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасы |
| Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләүнең хокукый нигезләре | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар китерү куркынычларын комплекслы профилактикалау стандарты |
| Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләүче | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасы максатлары | - Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү;<br>- контрольдәге затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру;<br>- мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүгә китерә торган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;<br>- мәҗбүри таләпләрне контрольдәге затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлылыкны арттыру;<br>- контрольлек эшчәнлеге системасының үтә күренмәлелеген арттыру. |

| | |
|---|---|
| Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасы бурычлары | - Контрольдәге мохит торышын бәяләү һәм контрольдәге затларга бирелгән куркынычлык категорияләреннән чыгып профилактика чараларының төрләре, формалары һәм интенсивлыгы бәйлелелеген билгеләү;<br>- контрольдәге затларның хәвефле тәртипкә мөнәсәбәтен үзгәртү, үз-үзен тотышы өчен уңай җаваплылык формалаштыру, намуслы үз-үзеңне тотуга мотивация булдыру;<br>- мәҗбүри таләпләрне даими ревизияләү һәм контрольдәге өлкәгә муниципаль контроль предметын тәшкил иткән мәҗбүри таләпләр комплексының реаль йогынтысын тәэмин итү буенча чаралар күрү;<br>- контроль эшчәнлегендә катнашучыларның барысында да мәҗбүри таләпләрне бердәм аңлау формалаштыру;<br>- позитив профилактика системасы чараларын булдыру һәм гамәлгә кертү; контрольдәге затларның хокукый грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән мәҗбүри таләпләр һәм аларны үтәү буенча кирәкле чаралар турында мәгълүматның үтемлелеген тәэмин итү юлы белән;<br>- контроль эшчәнлеге чыгымнарын һәм контрольдәге затларга административ йөкләнешне киметү;<br>- җайга салынулы өлкәдә ачыкланган куркынычсызлык проблемаларына һәм профилактик эшнең агымдагы торышына бәйле башка бурычлар |
| Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2026 ел |
| Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | - Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын киметү;<br>- контрольдәге субъектларның законга буйсынучы өлешен арттыру - контроль органның профилактик чаралар системасын үстерү;<br>- профилактиканың төрле алымнарын гамәлгә кертү;<br>- контроль орган эчендә профилактик эш технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү;<br>- контрольдәге субъектларның нәтиҗәле, закон үтәүче үз-үзен тотышы үрнәкләрен эшләү;<br>- контроль орган вазыйфаи затларының квалификацияле профилактик эшен тәэмин итү;<br>- контроль орган эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген арттыру;<br>- контрольдәге субъектларга административ йөкләнешне киметү;<br>- контрольдәге субъектларның хокукый грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү; |

| | |
|---|---|
| | - контрольдәге субъектлар тарафыннан контроль предметын аңлауның бертөрлелеген тәэмин итү;<br>- контрольдәге субъектларны намуслы тәртипкә мотивацияләү;<br>- башкалар. |

## 1 бүлек. Контроль төрен гамәлгә ашыруның агымдагы торышын анализлау, контроль органының профилактик эшчәнлегенең агымдагы үсешен тасвирлау, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасы хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларны характерлау

Контрольдәге затлар тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда кисәтү, әлеге бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатында, 2025 елда мондый хокук бозуларны профилактикалау чаралары тормышка ашырылмады.

## 2 бүлек. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын гамәлгә ашыру максатлары һәм бурычлары

1. Программаны тормышка ашыруның максаты булып тора:

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү;
- мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар китерү куркынычы янауны яисә зарар китерүне булдырмый калу;
- мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм зарар китерү куркынычы янауга яисә зарар китерүгә этәрә торган гамәлдәге һәм потенциаль шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;
- контрольдәге затларның социаль җаваплы, намуслы, хокукый үз-үзен тотышы модельләрен формалаштыру;
- контрольлек эшчәнлеге системасының үтә күренмәлелеген арттыру.

2. Программаны тормышка ашыруның бурычлары булып тора:

- зарар китерү мөмкинлеген яисә зарар (зыян) китерүнең куркынычын бәяләү (нинди кыйммәтләргә), аны киметүгә ярдәм итә торган профилактик чараларны эшләү һәм тормышка ашыру;
- зарар (зыян) китерү куркынычы яисә китерү факторларын, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, куркыныч янауларны бетерү яки киметү ысулларын билгеләү;
- контрольдәге мохит торышын бәяләү һәм контрольдәге затларга бирелгән куркынычлык категорияләреннән чыгып профилактика чараларының төрләре, формалары һәм интенсивлыгы бәйлелелеген билгеләү;
- контрольдәгечы затларның хәвефле тәртипкә мөнәсәбәтен үзгәртү, үз-үзен тотышы өчен уңай җаваплылык формалаштыру, намуслы үз-үзеңне тотуга мотивация булдыру;
- мәҗбүри таләпләрне даими ревизияләү һәм контрольдәге өлкәгә муниципаль контроль предметын тәшкил иткән мәҗбүри таләпләр комплексының реаль йогынтысын тәэмин итү буенча чаралар күрү;
- контроль-күзәтчелек эшчәнлегендә катнашучыларның барысында да мәҗбүри таләпләрне бердәм аңлау формалаштыру;

- позитив профилактика системасы чараларын булдыру һәм гамәлгә кертү; контрольдәге затларның хокукый грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән мәҗбүри таләпләр һәм аларны үтәү буенча кирәкле чаралар турында мәгълүматның үтемлелеген тәэмин итү юлы белән;

- контроль-күзәтчелек эшчәнлеге чыгымнарын һәм контрольдәге затларга административ йөкләнешне киметү.

## 3 бүлек. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү вакыты (ешлыгы)

«ТР Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмә нигезендә түбәндәге профилактик чаралар үткәрелә:

а) мәгълүмат бирү;

б) консультация үткәр;

2. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү сроклары, гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны күрсәтеп, программага кушымтада бирелгән.

## 4 бүлек. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасының нәтиҗәлелек күрсәткечләре

1. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләнә:

а) контрольдәге затларга карата контроль чараларның гомуми санынннан контроль чаралар үткәрү барышында ачыкланган бозулар өлеше – ____%.

Әлеге күрсәткеч контроль чаралар үткәрү барышында ачыкланган хокук бозулар санының, үткәрелгән контроль чараларның гомуми санына карата процент чагыштырмасы буларак исәпләнә;

б) контроль чаралар күләмендә профилактик чаралар өлеше – ___%.

Әлеге күрсәткеч профилактик чаралар санының үткәрелгән контроль чаралар санына карата мөнәсәбәте буларак исәпләнә. Күрсәтелгән күрсәткечнең ел саен артуы көтелә.

2. Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында мәгълүмат «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 30 статьясы нигезендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында доклад составына кертелә.

2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасына кушымта

**Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү сроклары (ешлыгы)**

| № | Чара төре | Чара формасы | Чараны гамәлгә ашыру өчен җаваплы бүлекчә һәм (яки) вазифаи затлар | Үткәрү сроклары (ешлыгы) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәгълүмат бирү | Контрольдәге затлар белән, аларга мәгълүмат бирү максатында, гавами чаралар (җыелышлар, киңәшмәләр, семинарлар) үткәрү | Авыл җирлеге Башлыгы | Ел дәвамында кирәк булган саен |
| | | Вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан контроль-күзәтчелек органнары адресына җибәрелгәндә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча кулланмаларны сайтта бастырып чыгару | Авыл җирлеге Башлыгы | Кергән саен |
| | | «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта төзекләндерү өлкәсендә контроль турында нигезләмәдә каралган мәгълүматны урнаштыру һәм аны актуаль хәлдә тоту | Авыл җирлеге Башлыгы | По мере обновления |
| 2. | Консультация үткәрү | Контроль-күзәтчелек органнары вазифаи затларының түбәндәге мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрүе:<br>1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;<br>2) контроль чараларны үткәрү ешлыгы;<br>3) контроль чаралар йомгаклары буенча карарлар кабул итү тәртибе; | Авыл җирлеге Башлыгы | Ел дәвамында (нигезләр булганда) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 4) контроль орган карарларына шикаять белдерү тәртибе. Консультацияләр шәхси мөрәҗәгать, телефон элемтәсе, электрон почта, видео-конференц-элемтә аша, язма запрос алганда - «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә язма рәвештә, шулай ук профилактик чара, контроль чара уздыру барышында башкарыла | | |